**Республика Татарстан**
**Совет Старо-Имянского сельского поселения**
**Сармановского муниципального района**
423373, с. Старый Имян,
ул. М. Вахитова,36 в

**Татарстан Республикасы**
**Сарман муниципаль районы**
**Иске Имэн авыл жирлеге Советы**
423373, Иске Имэн авылы,
М. Вахитов урамы, 36 в йорт

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**05 октябрь 2016 ел** **№34**

**Иске Имән авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 22, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 ст. 1 п., Иске Имән авыл җирлеге Уставының 11,12 ст. нигезендә Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге Советының "референдум үткәрү инициативасы турында "2016 елның 28 сентябрендәге № 33 карары нигезендә Иске Имән авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Иске Имән авыл җирлеге территориясендә 2016 елның 20 ноябренә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
"2017 елда Иске Имән авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешедән 200 сум күләмендә үзара салым акчасын кертүгә, I төркем инвалидларыннан тыш, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме?:

1) җирлек территориясендә физик культура һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тәэмин итү, җирлекнең рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру, 12,0 мең сум күләмендә, шул исәптән:
-Иске Имән һәм Сарысаз Тәкермән авылларында физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын уздыру өчен 12,0 мең сум күләмендә бүләкләр алу;

2) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру (урамнарны яктырту, территорияне яшелләндерүне дә кертеп) 43,4 мең сум күләмендә, шул исәптән:

- Иске Имән һәм Сарысаз Тәкермән авылларында урамнарны яктырту лампаларын алмаштыру, 7,0 мең сум күләмендә;
- урам утларына электр энергиясе өчен 4,0 мең сум күләмендә түләү;
-Иске Имән һәм Сарысаз Тәкермән т. п. чикләрендә 5,0 мең сум күләмендә аншлаг әзерләү;
-Сарысаз Тәкермән т. п. һәйкәлне ремонтлау 6,4 мең сум күләмендә.;
- Иске Имән авылында клуб өчен 6,0 мең сум күләмендә урындык сатып алу;
-Сарысаз Тәкермән т. п. да 15,0 мең сум күләмендә балалар урам комплексы сатып алу.

3) автомобиль юлларына, җирле әһәмияттәге күперләргә карата торак пунктлар чикләрендәге юл эшчәнлеге 2,0 мең сум күләмендә, шул исәптән:
- Иске Имән һәм Сарысаз Тәкермән авылларында юлларны кардан чистарту-2,0 мең сум.

4) 6,8 мең сум күләмендә көнкүреш калдыкларын һәм чүп-чар җыюны һәм чыгаруны оештыру, шул исәптән:
- Иске Имән авылында вакытлыча көнкүреш калдыклары һәм чүп-чар җыю урыннары 3,4 мең сум күләмендә;
-Сарысаз Тәкермән т.п. вакытлыча көнкүреш калдыклары һәм чүп-чар җыелу урыннарын 3,4 мең сум күләмендә җыештыру.

Барлыгы: 64,2 мең сум.

«ӘЙЕ» " ЮК»

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән 5 көн эчендә халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Сарман муниципаль районы
Иске Имән авыл җирлеге
Советы рәисе Р.Ә.Исламова